| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СТАРОШУГУРОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИСКЕ ШӨГЕР<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

2023 елның 3 июле №26

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2013 елның 18 декабрендәге 23 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законның 16 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацының үз көчен югалтуын тану хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2013 елның 18 декабрендәге 23 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

12 статьяның 5 пунктында «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 40.1 статьясында каралган очракта, капиталь төзелеш объектының архитектур-шәһәр төзелеше йөзен килештерү.» абзацын түбәндәге эчтәлекле абзац белән алмаштырырга: «капиталь төзелеш объектларының архитектур-шәһәр күренешенә таләпләр.».

2.Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында хәбәр итәргә: ТР, Лениногорск районы, Иске Шөгер авылы, Совет урамы, 1 йорт (җирле үзидарә бинасы); Иске Шөгер авылы, Совет урамы, 3 йорт (балалар бакчасы бинасы); Иске Шөгер авылы, М. Җәлил урамы, 33 йорт; Яңа Шөгер авылы, Гагарин урамы, 1а йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый порталында (https://tatarstan.ru) бастырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Иске Шөгер авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Советы рәисе Л.М.Шиһапова